музыкасыннан тыш), шул халык музыкасында иҗат итегез: татар сезне Чайковскийны, Глинканы яраткан кебек үк ихтирам итәр. Ә сез музыка дип тәкъдим иткән эклектикагызны «чын безнеңчә матур көй» итеп (урынлы рәвештә) таный алмаган халыкны зәвыксызлыкта (алты-бишлектә, наивныйлыкта)... гаеплисез. Халык «сабый» түгел, ә сез «сабый».

Чыганак: Мәйдан.- 2006.- № 2.- Б.42-45

# Шигырь — кеше җанының чәчкәсе ул

## *Сибгат Хәким иҗаты турында*

Сибгат Хәким. Бу ягымлы, сөекле исемне ишетү белән безнең күңелләребез рәхәтләнеп, җылынып китә. Сафлык, тыйнаклык һәм гаделлек символы булып яңгырый бу исем.

Без үзебезнең иң кадерле шагыйрьләребез Тукайдан, Такташтан, Җәлилдән, Кәримнән һәм Әхмәт Фәйзидән бик иртә аерылдык, аларның иҗади гомерләре күкрәп чәчкә аткан чакларында өзелде, әйтер сүзләре әйтелеп бетелмәгән хәлдә калды. Безнең халык аларны үзенең җырындагыча «күз керфекләрем талганчы карыйсым калган икән» дип, сагына-сагына, юксына-юксына яши. Менә шулар кебек үк кадерле шагыйрьләребезнең берсе булган Сибгат Хәким белән бер чорда, бер заманда гомер итәбез.

Без бүген аны татар совет әдәбияты хәзинәсенең алтын фонды булып кабул ителгән сокландгыч иҗаты өчен чын күңелдән хөрмәтлибез, олыларыбыз — өлкәннәргә хас рәвештә, күңел кулларыбыз белән башыннан сыйпап, ә кечеләребез, яшьләргә лаек рәвештә, хөрмәт белән аңа баш иеп, миллионнарча йөрәкләрнең рәхмәтен һәм сәламнәрен тапшырабыз.

Сибгат Хәким — кеше һәм шагыйрь буларак, үрнәк ителерлек тыйнак һәм гадел кеше. Әгәр бүген аны безнең туган илебез дулкынланып алкышлый икән — бу бер дә гаҗәп түгел: Хәкимне тудырган һәм үстергән халык үзе дә бик гадел һәм гуман халык бит.

Тукай бүләге лауреаты булган Сибгатебез чын мәгънәсендә лирик шагыйрь ул. Аның иң яхшы шигырьләренең барысы да халык тормышыннан, ил күңеленнән алынган һәм аларның һәрберсе шагыйрьнең үз йөрәк җылылары белән сугарылган. Хәким иҗатында ясалма темалар буенча язылган абстракт шигырьләр бөтенләй юк. Ул бары үзен бик нык дулкынландырган, үзе кичергән һәм язмый калу мөмкин булмаган темаларын гына сайлап алып иҗат итә. Аның һәр шигыре диярлек халык тормышына, тормыштагы вакыйгалар һәм конкрет кешеләргә кайтып кала. Хәким шигырьләренең исемнәре үк шуны күрсәтеп тора. Менә Хәкимнең «Фәрхинур», «Рамазан», «Туры Газзә», «Хәйрулла» дип аталган әсәрләренә, тормыштагы чын кешеләр үзләренең исемнәре белән үк шигырьгә килеп кергәннәр. «Усал диләр мине» шигырендәге Бүре Әсмасы, «Сары капкалы йорт» шигырендәге Сәлахи, «Почта егете» дигән шигырьдәге Касыйм һәм башкаларның барысы да безнең илдә гомер иткән реаль кешеләр алар.

Сибгат шигырьләренең тормышчанлыгын, реальлеген раслашуга тормыш үзе дә якыннан катнаша. Халык тарафыннан сайланган заседатель буларак судта утырган чагында, үзенең яңа бер темасы белән очраша ул. Судта халык арасында җиде яшьләрдәге бер нәни бала басып тора. Кем ул? Судка, тормышның шундый күңелсез төшенә нигә килгән бу сабый бала? Шагыйрь менә шул малай кисәгенең (Тукай әйтмешли, фирештә валчыгының) язмышы белән якыннан таныша. Бу тема Хәкимгә тынгылык бирми, шигырь ителеп язуны таләп итә һәм шагыйребез «Рамазан» дигән шигырен яза. Бу шигырь беренче юллары белән үк җанны, күңелне бөтереп, биләп ала.

Хәким гадел, гуманист шагыйрь ул. Тормышның ачысын шактый татыган һәм баласын — Рамазанны ташлап киткән Фәсахәтне сак кына, туганнарча гына шелтәли Хәким. Ләкин Рамазан йоклаган чагында да, кашларын җыерып куя. На-



Президиумда КПССның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табеев, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин

расыйның кашлары арасында «Әни мине нигә ташлап китте? Үсеп җитсәм, мин алай итмәм...» дигән шелтә ята. Менә ул күләме белән кечкенә генә, ләкин эчтәлеге, күтәргән мәсьәләләрнең мөһимлеге белән поэма дип аталырга хаклы булган искиткеч көчле, җанны тетрәтерлек чын һәм мөһим шигырь.

Әтнәнең балалар йорты директоры белән РОНО мөдире Хәкимнең менә шул шигырен укыйлар да үзара киңәшәләр. Шигырьне Фәсахәт яшәгән шәһәрнең прокурорына, Ташкентка җибәрәләр. Прокурор шигырьне Фәсахәткә тапшыра. Баласы һәм үзе турындагы шигырьне елый-елый, кат-кат укый Фәсахәт. Рамазанны үз янына алып китәргә дип, Әтнәгә кайта. Рамазан башта кача, әнисе белән китәргә теләми. Тик әнкәсенең чын күңелдән ялваруына ышангач кына Ташкентка китәргә риза була.

Менә бу Рамазан вакыйгасы, бер яктан, тормышның әдәби әсәрләр өчен тема булырлык хәлләргә никадәр бай икәнен күрсәтсә, икенче яктан, шагыйрьдә шул темаларны ачык күрерлек күңел күзе, зирәк таланты барлыгын да чагылдыра.

Хәкимнең, халык тормышы һәм язмышы белән бик нык бәйләнешле йөзләрчә шигырьләренең берсе «Юат син аларны» дип атала. Бу шигырьдә кычкырып яки барабан сыман дөбердәп торган бер генә сүз дә юк. Ул бик гади, бик табигый һәм тыйнак әсәр булып тоела. Ләкин бу шигырьне әдәбият кануннары буенча тикшерә башласаң, аңардагы эчтәлек һәм форма байлыклары турында диссертация язарга мөмкин булыр иде.

Ул өйдә бер песи, бер карчык,
Зурайткан рәсеме солдатның.

Хәкимнең «Юат син аларны» дигән шигыре менә шул сүзләр белән башланып китә. Ни өчен шагыйрь монда, карчык һәм песи белән беррәттән, өченче кеше итеп солдатның рәсемен алган соң? Өстән карaганда урынсыз һәм дөрес түгел кебек тоела бу. Ләкин Хәкимнең осталыгы, таланты шунда ки, бары кәгазь генә булган бу рәсемнең карчык өчен тере кеше кебек

булып тоелуын (бу турыда шуннан бүтән бер генә сүз кулланылмаса да) ачык итеп әйтә алган ул. Бу сыйфат Хәкимнең бик аз сүзләр аркылы чиксез зур фикер һәм хисләрне әйтә алу осталыгы булып тора.

Бу өйдә сөйли белүче бары карчык кына: песи һәм рәсем сөйләшми. Димәк, бу өйдә искиткеч, ялыктыргыч тынлык хөкем сөрә. Хәким моны бик кыска итеп, бөтенләй башка сүзләр белән һәм бик оста рәвештә әйтеп бирә. «Йөрүе дөресме, түгелме, / Тавышы ишетелсен сәгатьнең», — ди ул. Чөнки ятим, ялгыз карчык өчен сәгатьнең вакыт күрсәтүе түгел, ә әби белән сөйләшкән кебек итеп йөреп торуы кадерле. Бу әби шул тын, озын көннәрне ничек үткәрә соң?

Кимендә көнгә бер мәртәбә
Эш юктан актара ул өйне...
Кечкенә тартмада — язулар,
Тәсбихы, улының ордены.

Хәкимнең бу сүзләре кайбер коры җанлы, буш башлы кешеләрнең колакларын ук торгызадыр, бәлки: ничек инде, янәсе, безнең дәһри шагыйрь шигырьдә тәсбихне, ягъни «дин инвентарен» телгә ала?! Җитмәсә, совет ордены белән беррәттән телгә ала?!

Әгәр дә безнең арабызда менә шундый, акылга җиңелрәк кешеләр әле дә бар икән, аларга аңлатма бирүнең кирәге юктыр. Пентагонның, Штраус һәм Де Гольнең, Берлин проблемасы дигән сүзләрнең нәрсә икәнен белмиләрдер, бәлки. Ләкин безнең бу әбкәйләр дөньяны сугышка грифтар итәргә теләүче хәерсезләрнең, имгән сөтләре хәрам булгырыларның кемнәр икәнен бик яхшы беләләр.

Картайган, тәсбихлы куллардан
Ник тотмый бер түгел, ун Ходай,
«Сугыш» дип сак кына әйтүгә,
Ярылырга әзерләр бомбадай, —

ди шагыйрь алар турында.

Чәчкәләр — табигатьнең органик хәлгә, үсә һәм яши торган хәлгә килгән матдәнең — материянең җыры — шигыре алар. Ә шигырь һәм җыр — җир йөзендәге, табигатьтәге иң бөек затның, кеше җанының чәчкәсе ул. Чәчкәләр белән поэзия арасында ниндидер якын туганлык бар. Шагыйрьләр үзләренең шигырьләрендә һәрвакыт чәчкәләрне телгә алалар. Ә безнең Хәким чәчкәләргә әлегәчә беркем дә аяк басмаган сукмак аша, халык күңеле тудырган романтик сукмак аша килә. Ул, менә, үзенең туган-үскән якларында кырларда йөргәндә, шактый озын кәүсәле сары чәчәкләр янында, җиз кыңгырауларны хәтерләткән чәчәкләр янында тукталып кала. Шунда кырда йөргән малайлар ашыга-ашыга шагыйрь янына киләләр. «Кагыла күрмә, Сибгат абый, син бу чәчәкләргә, — диләр алар, — давыл чәчәге бу. Аңа кагылырга ярамый: кагылдың исә, давыл куба», — диләр малайлар. Бу очрашу шагыйрь йөрәгендә тирән эз калдыра һәм бу — халык романтикасы белән сугарылган сары чәчәкләр сугыш һәм тынычлык турындагы иҗтимагый шигырьгә — «Давыл чәчәкләре» дигән шигырьгә әверелә.

Хәким шигырьләре китабын серле бүлмәгә ишек ачкан кебек ачасың һәм шигырьгә күз саласың. Күз алдында гүя экран. Ул экранда гүя ниндидер рәсем төсмерләнә башлый. Күзләреңнән прожектор нуры төшергәндәй, караргаукырга керешәсең. Рәсем-картина ачыла бара һәм шигырьнең ахырына җиткәндә инде рәсемне тулы рәвештә күрәсең. Кайсы художник картинасы, кайсы рәссам рәсеме бу?

Юк, бу рәсемне бер рәссам да иҗат итмәгән әле, рәсем итеп төшермәгән әле. Бу әлегә бары тик Хәкимнең шигыре. Бу шигъри рәсемдә игеннәре җыелып алынган, бушап калган көзге кыр. Кырда салкынча җил исә. Ничектер тапталмый калган бердәнбер ялгыз зәңгәр чәчәк җилдә моңаеп, калгып утыра. Һәм суд залында икенче нәни бер чәчәк. Аның башында зәңгәр башлык. Кулына сөтле шешәсен тоткан хәлдә, аерылышырга килгән әттә һәм әннәсенә, аннары судьяларга карыйкарый: «Китик әле моннан, өйгә китик әле», дигәндәй, идәндә моңаеп утыра.

Бу шигырьнең соңгы юлы: «Менә — бөгелә зәңгәр чәчәк... ул кем белән күзне каршылар?» — дигән сүзләр белән тәмам була. Чынлап та, әтисендә калырмы, әллә әнисендә калырмы бу зәңгәр башлыклы нәни чәчәк? Аңа да тормышның көзге салкын җилләрендә чайкалырга туры килерме?

Хәкимнең бу шигырендә «Аерылырга ярамый» дигән бер генә сүз дә әйтелмәгән. Шулай да ул уйландыра, дулкынландыра. Чөнки шагыйрь үзе дә тирәнтен дулкынлана, безнең тормыштагы күңелсез яклар өчен үзе дә борчыла һәм аның борчылулары безгә — укучыларга да күчә.

Хәким шигырьләрендәге эчтәлек шигырьнең күләменә караганда әллә ничә тапкыр зур һәм киң. Укыган саен кечерәя, сүрелә бармый, ә зурая, арта, тулылана бара ул.

* * *

Синең чорда поэзиягә килеп кергән Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Әхмәт Исхак, Салих Баттал, Нури Арсланнар кебек олыларыбыз, хәзерге поэзиябезнең өлкәннәре буларак, урта һәм яшь буыннарның якын киңәшчеләре буларак, алдагы сафта баралар. Аларның табанына баса-баса диярлек, урта буын шагыйрьләребез Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Хисам Камалов, Әхсән Баяннар һәм яңа яшьләр Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановлар, Саҗидә Сөләйманова һәм Клара Булатова кебекләр шигырьнең олы юлында киләчәккә баруда дәвам итәләр.

Халык эченнән яңа талантлар килә тора. Безнең Татарстан язучылары сафына килергә әзерләнәләр. Син талантлы яшьләрне, Һади, беренче шигъри юлларыннан, беренче тавышларыннан ук таный идең. Хәзер дә шулай. Чын шагыйрь буласыларны беренче авазларыннан ук танып була. Менә аларның берсе: «Акчарлаклар әгәр ял итсә дә, дулкыннарга кунып ял итә» дип әйтеп, ике генә юллык бу шигъри сүздә никадәр тирән, тыгыз мәгънә ята. Бу могҗиза түгел. Бу хәзер табигый хәл. Шагыйрьләрне тудырган ил шундый, заман шундый, күрәсең. Яшьләрнең берсе — Кадыйр Сибгатуллин дигәне — бик шигъри итеп, моның сәбәбен дә әйтеп бирә. «Җырчы да, шагыйрь дә булма, ди, монда тор, монда ту, яшә дә!» Һәм үзенең лирик хисен дә «мәхәббәтне юк диюче булса, андый кеше сине күрмәгән», дип, афоризм кебек, канатлы сүз итеп әйтеп бирә ала.

Шагыйрь! Кем соң ул? Шагыйрь шигырь язучы гына түгел, шагыйрь — үзе шигырь ул. «Шигырь» дигән сүзне әйтү белән күңел күзе алдына Тукайлар, Есениннар килеп баса. Такташ шундыйларның берсе иде. 1923 елда Уралда, шагыйрь Такташ белән (аның беренче шигырьләре белән) очраштым. Гомер юлларымдагы иң бәхетле көннәремнең берсе булып истә калды. Аның талантлы, канатлы, тылсымлы шигырьләре җан азыклары булды, йөрәкне биләп, чорнап алды. Әйтеп бетермәслек бәхет бирде. Шундый шигырьләрне иҗат итә алган шагыйрь җирдән, анадан туып түгел, легендалар, эпослар, халык әкиятләре дөньясы эченнән килеп чыккандыр кебек тоелды. Гадәти, гади эш кенә түгел бу, чын талантның, иҗади кодрәтнең эше булып гәүдәләнешедер бу, дигән фикер тудырды. Такташның үзен күреп белгәч тә, аның белән иң якын дусларча бергә яшәгән елларда да бу тойгы үзгәрмәде. Безнең арага вакытлыча гына башка дөньядан килгән зат булып тоелды ул. Әле дә минем хәтеремдә ачылып җитмәгән тылсым булып тора ул. Һәм аның әдәби абыйсы булган Тукай да шулай. Ул халыкның балалары булганга күрә, аларның характерындагы күзгә чалынып торган нур офыклары төсмерләнә. Халык телендә бер легенда бар. Диңгездә давыл күтәрелгәндә, җилкән көймәләрне һәлакәттән коткару өчен, гаҗәп зур балык рәвешенә кергән Диңгез атасына корбан буларак, берәр фидакарь суга ташланырга тиеш булган. Тукай моны 1905 ел революциясеннән соң да, реакция чорында, иҗтимагый җирлеккә күчереп: